ГЛАВА ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ

Ул. Чехова, д.18, с. Верхний Услон, 422570

Чехов ур., 18 нче йорт, Югары ослан авылы, 422570

Тел.: (84379) 2-13-38, факс: (84379) 2-18-39. E-mail: sovet.uslon@tatar.ru, verhniy-uslon.tatarstan.ru

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

_______________ с. Верхний Услон _______________

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Макыл авыл җирлеге генераль планы проектын карау буенча иҗтимагый фикер алышуларны билгеләү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2013 ел № 131-ФЗ Федераль законына таянып, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы халкының җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүдә катнашу хокукын гамәлгә ашыру максатларында, «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендәге вәкаләтләрне яңадан бүлү турында» 23.12.2023 ел, № 131-ТРЗ Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы, Югары Ослан муниципаль районы Советының 04.06.2020 ел № 58-670 карары белән расланган Югары Ослан муниципаль районында иҗтимагый фикер алышуларны оештыру һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмә белән,

КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Макыл авыл җирлеге генераль планы проектын карау буенча иҗтимагый фикер алышулар билгеләргә.
2. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән проектны карау буенча җәмәгать фикер алышуларын оештыручы итеп Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлеген (алга таба - җәмәгать фикер алышуларын оештыручы) билгеләргә.
3. Иҗтимагый фикер алышуларны оештыручы – коллегиаль киңәшмә органы составын расларга:

- Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе А. А. Әхмәтшин;
- Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлеге башлыгы А. Д. Сәгъдиева;
- Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Советының оештыру-хокукый һәм кадрлар эше бүлеге җитәкчесе Н.В. Пичугина;

- Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Макыл авыл җирлеге башлыгы П. Е. Карпухин;

4. Җәмәгать фикер алышуларын оештыручыга җирле үзидарә турындагы, шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законнар нигезендә җәмәгать фикер алышуларын оештыруны һәм уздыруны тәэмин итәргә.

5. Иҗтимагый фикер алышулар үткәрү чорын 2026 елның 19 февраленнән 2026 елның 26 февраленә кадәр билгеләргә.

6. Иҗтимагый фикер алышуларны оештыручыга Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 5.1 ст. нигезендә иҗтимагый фикер алышулар башлану турында хәбәр әзерләргә.

7. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштыру юлы белән (https://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында (https://verhniy-uslon.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

8. Бу карарның үтәлешен контрольдә тотуны Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенә йөкләргә.

Югары Ослан муниципаль районы Башлыгы Е.А. Варакин